**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 гыйнвар № 1

г. Казань

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Балаларга мәктәпкәчә, гомуми һәм өстәмә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы кысаларында, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1597 нче карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын (алга таба – Чаралар комплексы) расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын Чаралар комплексын тормышка ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 гыйнвар, 1 нче карары белән расланды

**2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексы**

**1. Гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен Татарстан Республикасында тудырылган шартлар турында мәгълүмат**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнарының эшчәнлеге үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту, балаларны һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими рәвештә һәм массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыруга йөз тоткан. Бүгенге көндә әлеге эшнең билгеле нәтиҗәләре бар.

Татарстан Республикасында 2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү буенча «Киләчәк» – «Будущее» стратегиясе тормышка ашырылды, һәм анда гомуми белем бирүнең иң мөһим максатлары итеп балаларның физик һәм рухи сәламәтлеге билгеләнде.

Физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыру өчен тиешле инфраструктура булу аеруча әһәмияткә ия.

Татарстан Республикасының 1 142 гомуми белем бирү оешмасында (гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында 81,4 процент) 1508 спорт залы эшләп килә.

Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларының спорт-сәламәтләндерү инфраструктурасы түбәндәге объектлардан тора:

спорт мәйданчыклары – 1459;
хоккей тартмалары – 519;
футбол кырлары – 850;
бассейннар – 34;
тренажер заллары – 140;
теннис заллары – 101;
бию заллары – 211;
башка объектлар – 240.

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары базасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт юнәлешендәге түгәрәкләр һәм секцияләр эшли. Спортның түбәндәге уен төрләре буенча түгәрәкләр һәм секцияләр аеруча популяр:

волейбол – 801 (14 879 укучы);
баскетбол – 712 (19 045 укучы);
хоккей – 336 (5 912 укучы);
футбол – 388 (8 864 укучы);
мини-футбол – 488 (6 125 укучы).

Шулай ук көрәш төрләре, җиңел атлетика, өстәл теннисы, чаңгы ярышлары, шахматлар, туристлык буенча түгәрәкләр һәм секцияләргә дә ихтыяҗ зур.

Өстенлекле бурычларның берсе – муниципаль берәмлекләрнең спорт-сәламәтләндерү инфраструктурасы объектларыннан максималь файдаланып, спорт белән шөгыльләнүне массакүләмгә әйләндерү.

Физик культура дәресләрен үткәрү һәм дәрестән тыш спорт-сәламәтләндерү эшчәнлеген оештыру өчен, республиканың гомуми белем бирү оешмалары муниципаль дәрәҗәдәге спорт-сәламәтләндерү объектлары: спорт сарайларыннан, спорт комплексларыннан, боз сарайларыннан, йөзү бассейннарыннан, стадионнардан актив файдалана.

Гомуми белем бирү оешмаларының муниципаль спорт-сәламәтләндерү объектларыннан файдалануы турындагы мәгълүматлар таблицада китерелә.

| Күрсәткеч | 2012/2013 уку елы | 2013/2014 уку елы | 2014/2015 уку елы | 2015/2016 уку елы |
|---|---|---|---|---|
| Физик культура дәресләрен үткәрүче мәктәпләр саны/ укучылар саны | 624 (39,3%) / 161 309 (43%) | 621 (41,3%) / 175 176 (47%) | 624 (42,8%) / 183 662 (49,7%) | 605 (43,1%)/ 191 592 (51,4%) |
| Мәктәптән тыш спорт-сәламәтләндерү эшен оештыручы мәктәпләр саны/ укучылар саны | 1514 (96%)/ 285 103 (77%) | 1454 (96 %)/ 305 672 (82%) | 1415 (97%)/ 364 735 (98,7%) | 1363 (97,2%)/ 370 437 (98,8%) |

Россия Федерациясе Президентының 2010 ел, 30 июль, 948 нче Указы нигезендә 2014/2015 уку елында республикада Президент ярышлары һәм Президент спорт уеннары үткәрелде.

Әлеге чараларның максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
укучыларның хәрәкәтләнү активлыгы дәрәҗәсен билгеләү;
массакүләм мәктәп спортын үстерү;
сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
укучыларны физик культура һәм спорт белән даими рәвештә шөгыльләнүгә җәлеп итү.

Президент ярышларында 349 509 укучы катнашты, һәм бу Татарстан Республикасы укучыларының гомуми санында 96,3 процент тәшкил итте.

Президент спорт уеннарында 202 687 укучы катнашты, һәм бу 5 – 11 сыйныф укучыларының гомуми санында 95,7 процент тәшкил итте.

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары спортның уен төрләрен, аерым алганда, мәктәп баскетболын үстерүгә юнәлдерелгән проектларда актив катнаша.

2014/2015 уку елы сезонының «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионатында, республиканың 898 гомуми белем бирү оешмасыннан 16 000 артык укучы җәлеп ителеп, 1339 мәктәп командасы катнашты.

Татарстан Республикасында проектның үсеш динамикасы

| Күрсәткеч | 2010/2011 уку елы | 2011/2012 уку елы | 2012/2013 уку елы | 2013/2014 уку елы | 2014/2015 уку елы |
|---|---|---|---|---|---|
| Катнашучы мәктәпләр саны/катнашучы командалар саны | 384 / 495 | 560 / 590 | 641 /1060 | 745 / 1120 | 898/ 1339 |
| Катнашучылар саны | 2304 | 11 500 | 12 742 | 13 440 | 16 068 |
| Кайтартылган спорт формасы комплектлары саны | 432 | 432 | 432 | 432 | 432 |
| Кайтартылган туплар саны | 2 304 | 3 024 | 3 846 | 4 470 | 5 388 |

2014/2015 уку елында Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары «Хезмәткә һәм саклауга әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (алга таба – ХСӘ) апробацияләүдә катнашты.

2015 елда ХСӘ бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәүдә 259 868 укучы катнашты (республикадагы укучыларның гомуми санында 69,3 процент).

276 388 мәктәп укучысы (республикадагы мәктәп укучыларының гомуми санында 73,3 процент) ХСӘ АМС автоматлаштырылган мәгълүмати системасында теркәлде (укучыларның индивидуаль саны, шәхси кабинеты бар. Системада нәтиҗәләр теркәлә).

202 870 укучы нормативларны уңышлы үтте (ХСӘ комплексы нормативларын үтәгән мәктәп укучыларының гомуми санында 78 процент).

2015 елның 15 маеннан 25 маена кадәр ХСӘ бердәм декадасы үткәрелде, һәм анда 11 – 12 яшьтәге (ХСӘ комплексының III баскычы) һәм 13 – 15 яшьтәге (ХСӘ комплексының IV баскычы) укучылар катнашты. Декадада 46 202 укучы катнашты. Декада йомгаклары буенча 1 784 мәктәп укучысы ХСӘ комплексының мактау билгеләрен алачаклар:

96 кеше – алтын мактау билгесе;

650 – көмеш мактау билгесе;

1 038 – бакыр мактау билгесе.

2015 елның 17 маеннан 19 маена кадәр Чаллы шәһәрендә ХСӘ бөтенроссия физкультура-спорт комплексы фестивале (алга таба – Фестиваль) үтте. Фестивальдә катнашу өчен Казан, Чаллы шәһәрләреннән, Бөгелмә, Арча, Буа, Зәй, Лениногорск, Мамадыш, Саба, Кайбыч, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Кама Тамагы муниципаль районнарыннан укучылар чакырылды.

ХСӘ бердәм декадасының муниципаль этабы йомгаклары буенча әлеге районнардан булган балалар иң яхшы нәтиҗәләр күрсәтте. Фестиваль йомгаклары буенча 2015 елның 23 августыннан 28 августына кадәр Белгород шәһәрендә узган бөтенроссия Фестивалендә катнашу өчен Татарстан Республикасыннан 8 кешелек җыелма команда төзелде.

Фестиваль йомгаклары буенча Татарстан Республикасының җыелма командасы Россия Федерациясенең Фестивальдә катнашкан 75 субъекты арасыннан 12 нче, сыгылмалылыкка нормативларны үтәүдә 1 нче урын, вокал конкурсында гран-при алды.

Фестиваль йомгаклары буенча 8 катнашучы да алтын мактау билгесенең беренче ияләре булды.

ХСӘ комплексын популярлаштыру, Комплекс нормативын уңышлы үткән укучыларга ярдәм күрсәтү максаты белән, 12 ноябрьдән 15 ноябрьгә кадәр «Заречье» сәламәтләндерү лагере базасында көзге Фестиваль булып узды. Фестивальдә 13 – 15 яшьтәге (дүртенче яшь баскычы) 104 мәктәп укучысы катнашты.

Көзге Фестиваль йомгаклары буенча 101 мәктәп укучысы нормативларны мактау билгеләренә лаеклы рәвештә үтте:

37 – алтын билге;

47 – көмеш билге;

17 – бакыр билге.

Барлык мәгълүматлар автоматлаштырылган мәгълүмати системага (ХСӘ АМС) кертелде. 2015 ел йомгаклары буенча көзге Фестивальдә катнашучылар шулай ук мактау билгеләре алачак.

Ел саен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан муниципаль берәмлекләрнең спорт-сәламәтләндерү конкурсларында һәм проектларында катнашу нәтиҗәлелегә рейтингы төзелә.

2014/2015 уку елы йомгаклары буенча рейтингта Чаллы шәһәре, Лениногорск, Бөгелмә, Түбән Кама, Саба, Мамадыш муниципаль районнары алда бара.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 февраль, 73 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру 2016 елда түбәндәге күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

| Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | 2016 ел |
|---|---|
| Халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче халык өлеше, процент | 38,5 |
| Россия Федерациясенең җыелма спорт командаларына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчылар саны, кеше | 560 |
| Укучылар һәм студентларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче укучылар һәм студентлар өлеше, процент | 65,0 |
| 100 мең кешегә спорт корылмалары саны, берәмлек | 248 |
| Спорт объектларының бер тапкыр халык кабул итә алу мөмкинлеге, процент | 32,11 |
| Яшьләрнең гомуми санында башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган сәләтле яшьләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге проектлар һәм программаларда катнашкан яшьләр өлеше арту, процент | 45,0 |
| Социаль әһәмияттәге проектлар һәм программалар конкурсына тапшырылган заявкалар саны, берәмлек | 230 |
| Авыл яшьләренең гомуми санында социаль-икътисадый үсеш программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгы, процент | 56,2 |
| Балаларны һәм яшьләрне ялның оештырылган формаларына җәлеп итү, мең кеше | 215 |

**2. Авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре**

а) Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларын ремонтлау.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында авыл җирлегендә урнашкан 834 гомуми белем бирү оешмасының спорт заллары бар. Шулардан авыл җирлегендә урнашкан 490 гомуми белем бирү оешмасының спорт залларына ремонт таләп ителә.

2012 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү төбәк системасын модернизацияләү проекты кысаларында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 3 октябрь, б-1774 нче боерыгы) 33 гомуми белем бирү оешмасында агымдагы ремонт үткәрелде. Моннан тыш, 3 гомуми белем бирү оешмасында, шул исәптән авыл җирлегендә урнашкан 1 гомуми белем бирү оешмасында спорт заллары ремонтланды.

2013 елда капиталь ремонт программасы кысаларында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 20 октябрь, б-2129 нчы боерыгы) авыл җирлегендә урнашкан 81 гомуми белем бирү оешмасында спорт залларына ремонт үткәрелде.

Җылыту системасын, тәрәзәләрне алыштыру, түбәне ремонтлау эшләре үткәрелде.

2014 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 31 спорт залы ремонтланды.

2015 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 38 спорт залы ремонтланды.

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 38 спорт залында ремонт эшләре үткәрү планлаштырыла;

б) Булган аудиторияләрне физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт заллары итеп үзгәртү.

Физик культура дәресләрен үткәрү һәм дәрестән тыш спорт-сәламәтләндерү эшчәнлеген оештыру өчен, Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары муниципаль дәрәҗәдәге спорт-сәламәтләндерү объектлары: спорт сарайларыннан, спорт комплексларыннан, боз сарайларыннан, йөзү бассейннарыннан, стадионнардан, ишегалды спорт мәйданчыкларыннан актив файдалана.

2014 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча программа кысаларында булган бер аудитория физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт залы итеп үзгәртелде.

2016 елда әлеге эшләр күздә тотылмый;

в) Дәрестән тыш вакытта (гомуми белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча) (мәктәпкәчә белем бирүдән тыш) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучылар санын арттыру.

2016 елда – 1,6 процент, шул исәптән:

башлангыч – 1,3 процент;

төп – 1,9 процент;

урта – 1,6 процент.

г) Оешмаларда мәктәп спорт клубларын үстерү.

Татарстан Республикасында авыл җирлегендә урнашкан 123 белем бирү оешмасында мәктәп спорт клублары бар. 2016 елда өстәмә 33 клуб оештыру планлаштырыла.

д) Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының ачык яссы спорт корылмаларын спорт инвентаре һәм җиһазлары белән тәэмин итү.

2013 елдан Татарстан Республикасында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының ачык яссы спорт корылмаларын төзү һәм спорт җиһазлары белән җиһазландыру программасы тормышка ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары микрорайоннарында һәм паркларында универсаль спорт

мәйданчыкларын төзү максатларында акча бүлеп бирү турындагы 2013 ел, 4 декабрь, б-2486 нчы боерыгы нигезендә 2013 елда 59 ачык яссы спорт корылмасы төзелде.

2014 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең гомуми белем бирү оешмалары территориясендә 72 ачык яссы спорт мәйданчыгы төзелде.

2015 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары территориясендә 76 ачык яссы спорт мәйданчыгы төзелде.

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары территориясендә 80 ачык яссы спорт мәйданчыгы төзү күздә тотыла.

Авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, әлеге чараларны финанслау күләмнәре, шулай ук аларны тормышка ашыру буенча план-график тиешенчә бу Чаралар комплексына теркәлгән 1 – 3 нче кушымталарда китерелә.

___

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына 1 нче кушымта

## Авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2015/2016 уку елы башына Россия Федерациясе субъектында укучыларның гомуми саны | | | 1 | 374 937 |
| 2015/2016 уку елы башына авыл җирлегендә урнашкан оешмаларда Россия Федерациясе субъектының укучылары саны | Барлыгы | | 2 | 79 705 |
| | гомуми саннан процент | | 3 | 21,3 |
| | белем бирү дәрәҗәсе | башлангыч | 4 | 31 040 |
| | | төп | 5 | 41 199 |
| | | урта | 6 | 6 417 |
| Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының гомуми саны | | | 7 | 897 |
| Спорт заллары булган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының гомуми саны | | | 8 | 834 |
| Ремонт таләп ителә торган спорт заллары булган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 9 | 490 |
| | спорт заллары булган оешмаларның гомуми санынннан % | | 10 | 58,8 |
| Спорт заллары ремонтланган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 11 | 38 |
| | Тормышка ашыру вакыты | | 12 | 2016 ел, 31 декабрь |
| Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен аудиторияләрне спорт заллары итеп үзгәртүгә ихтыяҗлары булган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 13 | 0 |
| | оешмаларның гомуми санынннан % | | 14 | 0 |
| Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен булган аудиторияләре спорт заллары итеп үзгәртеп ясалган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | Барлыгы | | 15 | 0 |
| | Тормышка ашыру вакыты | | 16 | 0 |
| Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында дәрестән тыш вакытта гомуми белем бирүнең | Белем бирү дәрәҗәсе | Башлангыч | 17 | 27 653 |
| | | Төп | 18 | 36 668 |
| | | Урта | 19 | 5 262 |

<table>
<tr><td>һәр дәрәҗәсе буенча (мәктәпкәчә белем бирүдән тыш) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучылар саны</td><td></td><td>Барлыгы</td><td>20</td><td>69 583</td></tr>
<tr><td rowspan="5">Дәрестән тыш вакытта (гомуми белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучылар өлеше арту, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш</td><td rowspan="5">Белем бирү дәрәҗәсе</td><td>Башлангыч</td><td>21</td><td>1,3%</td></tr>
<tr><td>Төп</td><td>22</td><td>1,9%</td></tr>
<tr><td>Урта</td><td>23</td><td>1,6%</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>24</td><td>1,6%</td></tr>
<tr><td>Тормышка ашыру вакыты</td><td>25</td><td>2016 ел, 31 декабрь</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Мәктәп спорт клублары булган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны</td><td colspan="2">Барлыгы</td><td>26</td><td>123</td></tr>
<tr><td colspan="2">оешмаларның гомуми саныннан %</td><td>27</td><td>13,7</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында оештырылган мәктәп спорт клублары саны арту</td><td colspan="2">Барлыгы</td><td>28</td><td>33</td></tr>
<tr><td colspan="2">Тормышка ашыру вакыты</td><td>29</td><td>2016 ел, 31 декабрь</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ачык яссы спорт корылмаларын спорт инвентаре һәм җиһазлары белән җиһазландыруга ихтыяҗлары булган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны</td><td colspan="2">Барлыгы</td><td>30</td><td>0</td></tr>
<tr><td colspan="2">оешмаларның гомуми саныннан %</td><td>31</td><td>0</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ачык яссы спорт корылмалары спорт инвентаре һәм җиһазлары белән җиһазландырылган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны</td><td colspan="2">Барлыгы</td><td>32</td><td>0</td></tr>
<tr><td colspan="2">Тормышка ашыру вакыты</td><td>33</td><td>-</td></tr>
</table>

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына 2 нче кушымта

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын финанслау күләмнәре

<table>
<tr><th rowspan="3">Т/с</th><th rowspan="3">Чаралар исеме</th><th colspan="5">Финанслау күләмнәре, мең сум</th></tr>
<tr><th rowspan="2">Барлы-гы</th><th colspan="4">шул исәптән</th></tr>
<tr><th>федераль бюджет акчасы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җирле бюджет акчасы</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td></tr>
<tr><td>1.</td><td>Спорт залларын ремонтлау</td><td>57 000</td><td>42 000</td><td>15 000*</td><td>0</td><td>0</td></tr>
<tr><td></td><td>БАРЛЫГЫ</td><td>57 000</td><td>42 000</td><td>15 000*</td><td>0</td><td>0</td></tr>
<tr><td colspan="7">* Акча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында күздә тотылды.</td></tr>
</table>

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына 3 нче кушымта

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын тормышка ашыру буенча план-график

| Т/с | Чаралар исеме | Чараларны тормышка ашыру вакыты | | | | Чараларны тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2016 елның I кварталы | 2016 елның II кварталы | 2016 елның III кварталы | 2016 елның IV кварталы | |
| 1. | Спорт залларын ремонтлау | x* | x | x | x | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| *«Х» билгесе белән хисап кварталында үткәрелә торган чаралар билгеләнде. | | | | | | |

F:\KARAR\2016\1-1.docx